ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКУЮКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422741 Республика Татарстан Атнинский район с. Нижний Куюк Тел. 3-32-47

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» август 2024 ел № 6

**«Капиталь төзелеш объектын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 15 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану турында**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Капиталь төзелеш объектын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 15 номерлы карарын;

2) «Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 30.07.2021 ел №15 карары белән расланган Капиталь төзелеш объектын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 22 декабрендәге 23 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әтнә
муниципаль районы Түбән Көек
авыл җирлеге башлыгы: Галиахметов Д.М.